ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 11.08.2026

**К А Р А Р** № 585

**Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2017 елның 13 февралендәге 389 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Биектау районы прокуратурасының 2026 елның 16 июлендәге 02-08-01 номерлы протестын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «Тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча ведомствоара комиссия төзү турында» 2017 елның 13 февралендәге 389 номерлы карарына (07.04.2017 № 902, 09.08.2017 № 2022, 08.05.2018 № 966, 16.12.2019 № 2396, 26.02.2020 № 250, 16.06.2023 № 757 редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карар преамбуласында «2010 елның 30 декабрендәге УП-891 номерлы «Тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча Республика ведомствоара комиссиясе мәсьәләләре» сүзләрен «2014 елның 25 февралендәге УП-217 номерлы «Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен арттыру, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм алардан файдалану мәсьәләләре буенча Республика ведомствоара комиссиясе турында» сүзләренә алмаштырырга, шулай ук «, Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 26 маендагы 359 номерлы нигезләмәсенә таянып,» сүзләрен төшереп калдырырга.

1.2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан 2017 елның 13 февралендәге 389 номерлы карары белән расланган 1 нче кушымтаны, әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә, яңа редакциядә бәян итәргә.

1.3. Халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе турындагы нигезләмәнең 3.4 пунктын (Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 13 февралендәге 389 номерлы карары белән расланган 2 нче кушымта) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Ачыкланган хокук бозулар турында мәгълүматны контрольдә тотучы һәм хокук саклау органнарына аларның компетенцияләре нигезендә чаралар күрү өчен җибәрергә».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында (https://vysokaya-gora.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Җитәкче Р.Ф.Хәкимуллин

1 нче кушымта

Халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе составы
(килешү буенча)

| | | |
|---|---|---|
| Хәкимуллин Р.Ф. | - | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |
| Вәлиулллина Р.Ш. | - | Биектау районының финанс-бюджет палатасы рәисе, комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча); |
| Тюрина Т.И. | - | «Татарстан Республикасы Финанс-бюджет палатасы» МКУнең фаразлау һәм анализлау бүлеге башлыгы, комиссия секретаре; |

Комиссия әгъзалары:

| | | |
|---|---|---|
| Булгаков М.Р. | - | Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; |
| Хисаметдинов Р.Ш. | - | Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары; |
| Идиятуллина Г.Р. | - | Татарстан Республикасы буенча 3 нче салым хезмәтенең районара инспекциясе камераль тикшерүләр бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Җамалиева З.Т. | - | «Биектау районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ бүлегенең әйдәүче белгече (килешү буенча); |
| Абрамов А.А. | - | Биектау районы буенча Россия Эчке эшләр министрлыгы бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Кәримова Э.Г. | - | Биектау районындагы клиент хезмәте (бүлек хокукларында) җитәкчесе |
| Гарифуллина Г.Г. | - | ТР Биектау муниципаль районы «Салих Сәйдәшев исемендәге сәнгать мәктәбе» ӨББ МБУ методисты, ТР Биектау муниципаль районы профсоюзлар оешмаларының координация советы рәисе, мәдәният |

| | | |
|---|---|---|
| | | хезмәткәрләре профсоюзының район комитеты рәисе (килешү буенча); |
| Сабирова А.И. | - | Биектау муниципаль районы Советының юридик бүлеге башлыгы (килешү буенча). |